**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чубар-Абдул авылы №36 27.10. 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 2014 елның 6 августындагы 113 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (12.11.2015 №18, 06.12.2016 №51, 23.04.2019 №136, 11.02.2020 №167, 15.03.2021 №22 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 16 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Чубар-Абдул авыл җирлеге советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 2014 елның 6 августындагы 113 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» карарына (12.11.2015 №18, 06.12.2016 №51, 23.04.2019 №136, 11.02.2020 №167, 15.03.2021 №22 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәнең 1 бүлегендә 6, 7 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы (подданствосы) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы;

7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н. Ә. Фәтхетдинов